| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 15 апрель № 226

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль проектлар конкурсларын үткәрү турында» 2005 ел, 7 апрель, 167 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль проектлар конкурсларын үткәрү турында» 2005 ел, 7 апрель, 167 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 07 февраль, 72 нче, 2011 ел, 07 октябрь, 837 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры А.Р.Шәфигуллин» сүзләрен «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль проектларның республика конкурслары турында нигезләмәдә:

II бүлекнең унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль проект – теге яки бу социаль мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерелгән чаралар системасын гамәлгә ашыруны мәгълүмати һәм финанс-икътисадый нигезләү, аны тормышка ашыру вакыты 6 айдан алып 12 айга кадәр. Бу чакта проектны тормышка ашыру вакыты тәмамлану акча биргән елдан соң килә торган елның 1 октябреннән дә соңга калмаска тиеш.»;

5.6 пунктның дүртенче абзацында «шәхси максатчан финанслау турында шартнамә буенча акчаны оешмалар тарафыннан куллануны, шул исәптән» сүзләрен «Конкурс җиңүчеләренә бүлеп бирелгән акчаны максатчан куллануны, шул исәптән аларны куллану шартларын һәм тәртибен саклауны, шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

VII бүлектә:

7.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Конкурс җиңүчеләренә акча бирү Вәкаләтле орган һәм Конкурс җиңүчеләре арасында төзелә торган шартнамәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Шартнамә Конкурс комиссиясе Конкурс җиңүчеләре исемлеген раслаган көннән соң 30 көн эчендә төзелә.

Шартнамәнең формасы, шулай ук вакытлары һәм шартнамәнең әлеге Нигезләмәдә билгеләнмәгән бүтән шартлары Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

Шартнамәдә бирелә торган акчаның максатчан билгеләнеше һәм аның зурлыгы, акчаны бирү тәртибе һәм аны күчерү вакытлары, шартнамә шартларын бозган өчен җаваплылык, акчаны куллану турында хисап бирү тәртибе һәм формасы, бүлеп бирелгән акчаны максатчан кулланмаган һәм/яки аны биргәндә куелган таләпләрне бозган очракта акчаны кире кайтару тәртибе һәм вакытлары, акчаның хисап финанс елында кулланылмаган өлешен акча алучылар тарафыннан кире кайтару очраклары, акча алучыларның Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан акча бирү һәм куллану шартларын, максатларын, тәртибен саклауны тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы күздә тотыла.

Вәкаләтле орган тарафыннан акчаны күчерү Вәкаләтле орган өлешләп максатчан финанслау турында шартнамәгә имза куйганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә Конкурс җиңүчеләренең исәп-хисап счетына өлешләп максатчан финанслау турында шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

Конкурс җиңүчеләре акча керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтер исәбе алып бара.»;

түбәндәге эчтәлекле 7.6 – 7.8 пунктлар өстәргә:

«7.6. Вәкаләтле орган һәм (яки) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының тиешле таләбен алганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә түбәндәге очракларда Конкурс җиңүчеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

Конкурс җиңүчеләренең әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән акчаларны бирү шартларын бозу факты билгеле булганда;

Конкурс җиңүчеләре акча алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар, документлар һәм акчаны тоту турында хисаплар тапшырганда;

бирелгән акча максатчан кулланылмаганда.

Бирелгән акчалар максатчан кулланылмаган очракта максатчан кулланылмаган суммада акча кире кайтарылырга ише.

Шартнамәләрдә каралган очракларда акчаның хисап финанс елында кулланылмаган өлеше Конкурс җиңүчеләре тарафыннан проектны тормышка ашыру вакыты тәмамланган көннән соң 30 көн эчендә агымдагы финанс елында, әмма агымдагы финанс елының 1 декабреннән дә соңга калмый Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Конкурс җиңүчеләре тарафыннан акчаларны ирекле рәвештә кире кайтару вакытлары бозылганда Вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче һәм алтынчы абзацларында билгеләнгән вакыт узган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 7 көн эчендә әлеге акчаларны Россия  Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча чаралар күрә.

7.7. Конкурс җиңүчесе Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының таләбе буенча акчаны максатчан куллануны тикшерүне гамәлгә ашыру өчен башкарылган чыгымнарны раслый торган документлар (төп нөсхәләрен һәм/яки оешма таныклаган күчермәләрен) тапшырырга тиеш.

7.8. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы законнарда билгеләнгән тәртиптә акчаны алучыларга бирүнең шартлары, максатларын һәм тәртибен саклауны тикшерүне гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков